ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КӘЗКӘЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

42361, Кәзкәй авылы,
Беренче май ур., 2 а нчыйорт.
Тел.3-44-46

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КАЗКЕЕВКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423761, село Казкеево,
ул. Первомайская,дом 2а,
Тел. 3-44-46

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«15» ноября 2024 года** **№ 1**

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Актаныш муниципаль районының Тыңламас авылы җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Актаныш муниципаль районының “Кәзкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 маддәсе нигезендә Кәзкәй авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. 2024 елның 25 ноябрендә 18.00 сәгатькә Актаныш муниципаль районының Кәзкәй авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: 2025 елда 18 яшькә җиткән һәр гражданнан яшәү урыны җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар күрсәткән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация кысаларында мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаиләләре әгъзаларыннан, Украинада махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, аларның саны җирлек халкының гомуми санының 30 процентыннан артмаска тиеш, гражданнардан һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән:
- автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;
- җирлек чикләрендә халыкны электр белән тәэмин итүне һәм су белән тәэмин итүне оештыру;
өчен шартлар тәэмин итү өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасын бер тапкыр түләү кертүгә риза булырсызмы?

“ӘЙЕ” “ЮК”

3. Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Тыңламас авылы, Октябрь урамы, 72Б йорт адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.
4. Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл башкарма комитетының гражданнар

җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны Кәзкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә.
6. Башкаруны тикшереп торуны үземдә калдырам.

Кәзкәй авыл җирлеге Советы башлыгы: _____________ Шайхуллин Р.Р.